ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.01.2025 п.г.т. Алексеевское № 1

**Алексеевск муниципаль районында «Татарстан Республикасының иң яхшы ел территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсын үткәрү буенча муниципаль конкурс комиссиясен төзү турында**

«Татарстан Республикасының иң яхшы ел территориаль иҗтимагый үзидарәсе «Республика конкурсы турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 1 июнендәге 391 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе»республика конкурсы турындагы Нигезләмә нигезендә, һәм «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе президиумының 28.12.2024 ел, № ПР-136-1 карары белән

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районында «Татарстан Республикасының иң яхшы ел территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын үткәрү буенча муниципаль конкурс комиссиясе төзергә һәм аның эш регламентын (1,2 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// /alekseevskiy.tatarstan.ru)урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_10.01.2025_ № _1_
карарына 1 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районында «Татарстан Республикасының иң яхшы ел территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын уздыру буенча муниципаль конкурс комиссиясе**
**Составы**

**Комиссия рәисе:**
Леденцов О.Н. – Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

**Комиссия рәисе урынбасары:**
Свистунов И.К. – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча)

**Комиссия секретаре:**
Увакина В.В. – Алексеевск шәһәр җирлеге Советы Рәисе урынбасары (килештерү буенча)

**Комиссия әгъзалары:**
Тимонина Н.Ю. – «Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУның Алексеевск районы буенча бүлек башлыгы (килештерү буенча)

Йосыпова Г.Ә. – Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе.

**Башкарма комитетының**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_10.01.2025_ № _1_
карарына 2 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районында «Татарстан Республикасының иң яхшы ел территориаль иҗтимагый үзидарәсе» Республика конкурсын уздыру буенча муниципаль конкурс комиссиясенең эш Регламенты**

1. «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсының Алексеевск муниципаль районындагы муниципаль конкурс комиссиясе утырышы (алга таба - Комиссия), әгәр анда аның исемлек составындагы әгъзаларның кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы.

2. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен комиссиядә катнашучы әгъзаларның 50 проценттан артыграгы тавыш биргән булса, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

3. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә һәм Комиссия рәисе һәм әгъзалары тарафыннан Комиссия утырышы уздырылган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә имзалана.

4. Комиссия заявкаларны кабул итү срогы башланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә конкурсның I этабында катнашуга заявкаларны кабул итә һәм терки.

5. Комиссия заявкаларны кабул итү тәмамланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә конкурсның I этабында катнашуга тапшырылган заявкаларны «Татарстан Республикасының иң яхшы ел территориаль иҗтимагый үзидарәсе» Республика конкурсы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 1 июнендәге 391 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе»республика конкурсы турындагы Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) 4 нче кушымта нигезендә бәяли һәм конкурсның II этабында катнашуга дәгъва кылучы катнашучыларны билгеләнгән тәртиптә билгели.

6. Конкурсның I этабын уздыру йомгаклары буенча Комиссия конкурсның II этабына тапшыралар:

1) «Татарстан Республикасының иң яхшы ел территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсының II этабында катнашу турында Нигезләмәгә 2.1 нче кушымтадагы форма буенча гариза;

2) комиссия төзелгән һәм аның составы расланган муниципаль хокукый актның күчермәсе;

3) конкурсның I этабында катнашучыларның барысы исемлеге;

4) муниципаль конкурс комиссиясе рәисе имзалаган муниципаль конкурс комиссиясе утырышының йомгаклау беркетмәсе;

5) Нигезләмәнең 3.9 пункты нигезендә конкурсның II этабында катнашуга дәгъва кылучы катнашучыларның заявкалары.

7. Комиссия карарларына катнашучылар һәм дәгъвачылар тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

**Башкарма комитетының**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**